КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июль г.Казань № 884

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 август, 693 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы турында нигезләмәдә:

3.2 пунктның бишенче абзацында «, учреждениеләрдә, ведомстволарда» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Координация советы эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм мәгълүмати-методик тәэмин итүне үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәэмин итә.»;

Күрсәтелгән карар белән расланган Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 26 июль, 884 нче карары редакциясендә)

Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы
составы

| | |
|---|---|
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Ведомствоара координация советы рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Ведомствоара координация советы рәисе урынбасары |
| Булгаков Олег Михайлович | «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының башкарма директоры, Ведомствоара координация советы секретаре (килешү буенча) |

Ведомствоара координация советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшит улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Авдонина Любовь Геннадьевна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Әхмәтханов Җәүдәт Йосыф улы | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Галиев Илнур Наил улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кондратова Наталья Владимировна | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшмәкәрлекне һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры |
| Макаров Андрей Владимирович | «Татарстан Республикасында Стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директорының сыйфат белән идарә итү буенча урынбасарын (килешү буенча) |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Сафиуллин Илсур Миңнур улы | «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Фаттерахманов Ленар Рифат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы |
| Хәкимҗанов Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Хисаметдинов Алмаз Гаптерәүф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы. |